ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05 02 2024 г. № 96

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга ата-аналар түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләү тәртибенә (алга таба-Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Тәртипнең 1.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Компенсация шулай ук теркәлгән никахта торучы һәм тормыш иптәшенең баласының (балаларының) биологик ата-анасы булмаган очракта әлеге Тәртипнең 1.3. пунктының 5, 6, 7, 8 абзацларында күрсәтелгән гражданнарга билгеләнә һәм түләнә.»;

Тәртипнең 2.1. пунктын дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«никахлашу турында таныклык күчермәсе (түбәндәге Тәртипнең 1.3 пунктының 5, 6, 7, 8 абзацларында күрсәтелгән гражданнар өчен);».

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов